ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елнын 22 апрель** **Чистай шәхәре** **№ 201**

2020 елның II кварталына
Чистай муниципаль районы буенча
торакның гомуми мәйданының
1 квадрат метрының уртача базар бәясе
турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2020 елның 13 мартында кабул ителгән «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында»гы 122/пр Боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарның барлык категорияләренә дә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2020 елның Ⅱ кварталына Чистай муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда) 53024 (илле өч мең егерме дүрт) сум күләмендә расларга, аларга күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчасы хисабына торак бина сатып алу (төзү) өчен бирелә.

2.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне ТР Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов